СОВЕТ ЯНГУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЯҢГУЛ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«25» сентябрь 2018 ел № 78

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча жирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясына, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына, Яңгул авыл җирлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, «Яңгул авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 18 сентябрендәге 77 номерлы Яңгул авыл җирлеге Советы карары, «Яңгул авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү инициативасын тәкъдим итү турында» 2018 елның 18 сентябрендәге 11 номерлы Яңгул авыл җирлеге Башкарма комитеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2018 елның 18 ноябренә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга: "2019 елда Яңгул авыл җирлегендә яшәүче 18 яше тулган, референдумда тавыш бирү хокукына ия булган һәр кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?:

- Яңгул авылында Таулы һәм Тау асты урамнары арасындагы күперне капиталь ремонтлау;
- Совет, Яшьләр, Тау асты урамнарындагы юлларны тәртипкә китерү;
- Азатлык, Таулы, Муса Җәлил урамнарындагы юлларны ремонтлау;
- Янгынга каршы 2 гидрант урнаштыру, янгынга каршы колонкалар һәм аларга комплектлау әйберләре сатып алу
- Иске Көшкәт авылында Бөек Ватан сугышы елларында һәлак булучыларга

һәйкәл төзү;
-Янгынга каршы гидрант урнаштыру, янгынга каршы колонкалар һәм аңа комплектлау әйберләре сатып алу.

“ЭЙЕ” “ЮК”

3. Яңгул авыл җирлеге Советы карары нигезендә, аерым юнәлешләр буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җыелган акчаны экономияләү очрагында, экономияләнгән акчалар референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелә.
4. Әлеге карарны «Хезмәт» район газетасында һәм pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар аңа имза куелган көннән үз көченә керә.

поселения

Авыл җирлеге башлыгы: Р.Г.Гарипов